ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_21.02.2023_ Мөслим № _86_

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (2019 елның 6 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы ред.) һәм әлеге законның кушымтасында бирелгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы, «Торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасы һәм дәүләт торак программалары буенча торак урын бирү нормасы турында» 2006 елның 8 сентябрендәге 157 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына һәм «Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Торак базарын тикшерү турында» 2023 елның 8 февралендәге 29 номерлы хатына таянып, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча сатып алуның базар хакының түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге чик күләмен билгеләргә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 964 557,00 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1 227 618,00 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1 578 366,00 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 104 488,00 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 2 630 610,00 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 3 156 732,00 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 3 682 854,00 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 4 208 976,00 сум.

1.2. Исәпләүләр буенча гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткече күләме (1нче кушымта) тәшкил итә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен: 14 614,50 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен: 9300,13 сум – гаиләнең һәр әгъзасына;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен: 7971,54 сум – гаиләнең һәр әгъзасына.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасыры Д.З.Мухаметдиновка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Сәлихҗанов**

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 21 февраль
86 номерлы карарына
кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен исәпләп чыгару.**

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 – (1 + ПС) – КП ) / (0,3 х РС), биредә:

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ= НП х РС х РЦ, биредә:

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны;

РЦ – Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе;

ПС – бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (2022 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән ставкасы елга 8,62%, ягъни 8,62/100/12=0,005 – айга);

КП – кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (2023 елның гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының ипотека буенча торак кредиты буенча уртача исәпләнгән вакыты 292,1 ай);

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,3 – кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы

«Татарстан Республикасының бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2023 елның 8 февралендәге 29 номерлы хаты нигезендә 2023 елда Мөслим муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 29 229,00 сум тәшкил итә.

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләү:

| НП - тора | СЖ - торак урын сатып | РС - гаилә | РЦ - торак | ПС - Кредит | КП - кредит | Кредит суммасы | кредит буенча | ПД - керемнең |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| к урынның нормасы (кв. м) | алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | әгъзалары саны (кеше) | урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | буенча айлык процент ставкасы, (уртача еллык – 8,62%) (8,62/100/12) | буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | белән фатир бәясенең чагыштырмасы | түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы. | иң чик күләме (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 8 | 9 | 9 |
| 33 | 964557,00 | 1 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 0,3 | 14614,50 |
| 42 | 1227618,00 | 2 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 0,6 | 9300,13 |
| 54 | 1578366,00 | 3 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 0,9 | 7971,54 |
| 72 | 2104488,00 | 4 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 1,2 | 7971,54 |
| 90 | 2630610,00 | 5 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 1,5 | 7971,54 |
| 108 | 3156732,00 | 6 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 1,8 | 7971,54 |
| 126 | 3682854,00 | 7 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 2,1 | 7971,54 |
| 144 | 4208976,00 | 8 | 29229,00 | 0,005 | 292,1 | 0,7 | 2,4 | 7971,54 |